РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОШКИ-ШЕМЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘМӘК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

« 22 » август 2025 ел　　　　　　　　　　№ 19

Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитетының
2021 елның 01 июлендәге
12 номерлы «Кулланылган терекөмешле
лампалар туплану урыннары турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Кулланылган терекөмешле лампаларның туплану урыннары турында» 2021 елның 01 июлендәге 12 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә::

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урынының (урыннарының) урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Шәмәк
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе　　　　　　А. Ф. Әхмәтҗанов